Республика Татарстан
ГЛАВА ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
423950, п.г.т.Уруссу ул.Пушкина, 38
тел.: (85593) 2-80-13
факс: (85593) 2-62-20

Татарстан
Республикасы
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛ
РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ
423950, Урыссу ш.т.б. Пушкин урамы, 3
тел.: (85593) 2-80-13
факс: (85593) 2-62-20

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ  КАРАР

"25" 06 2018г.  № 55

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль
районы Советында һәм Башкарма комитетында
гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау һәм
шәхси кабул итүне тәэмин итү буенча
Эш тәртибен раслау турында

2006 елның 2 маеннан булган "Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында"гы 59 санлы Федераль законга ярашлы гражданнар мөрәҗәгатьләрен вакытында карау максатында, 2008 елның 25 декабреннән булган "Коррупциягә каршы көрәш турында"гы 273 санлы Федераль Законга, 2003 елның 12 маеннан булган "Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында"гы 16 санлы Татарстан Республикасы Законына, Министрлар Кабинетының 2006 елның 13 ноябреннән булган "2006 елның 2 маеннан булган шәхси кабул итүне тәэмин итү буенча Татарстан Республикасы дәүләт власте органнарының "Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында"гы 159 санлы Федераль Закон таләпләренә ярашлы шәхси кабул итүне тәэмин итү буенча дәүләт власте органнары бурычлары турында"гы 537 санлы нигезләмәсенә, шулай ук гражданнарның җирле үзидарә органнарына тәкъдимнәр, гаризалар, шикаятьләр белән мөрәҗәгать итүләренә конституцион хокукны гамәлгә ашыру максатында карар бирәм:

1.Кушымтага ярашлы Ютазы муниципаль районы Советында һәм башкарма комитетында гражданнарны шәхси кабул итүне тәэмин итү турында гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау буенча Эш тәртибен расларга.

2. Ютазы муниципаль районы Советы һәм Башкарма комитеты вазифаи затларына:

- гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау һәм шәхси кабул итүне оештыру буенча Эш тәртибендә бәян ителгән рекомендацияләрне файдаланырга;

- гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау, гражданнарны шәхси кабул итүне уздыру һәм аларның проблемаларын объектив чишү өчен мөһим булган шартларны тәэмин итәргә;

- кабул итү көнендә район чараларын планлаштырмаска.

3. Ютазы муниципаль районы халкына Ютазы муниципаль районы сайты аша гражданнарның язма һәм телдән мөрәҗәгатьләре белән эшләү практикасы һәм аларны карау нәтиҗәләре турында даими рәвештә мәгълүмат бирергә.

4. Әлеге карарны Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Ютазы муниципаль районы Башлыгының 2010 елның 26 февраленнән булган "Татарстан Республикасының Ютазы районы Советында гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау буенча муниципаль хезмәт күрсәтү административ регламентын раслау турында"гы 11 санлы карарын көчен югалткан дип танырга.

6. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны Ютазы муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесе Г.С. Фәхертдинөвага йөкләргә.

Ютазы муниципаль районы Башлыгы Р.М. Нуриев.

Кушымта №1
Ютазы муниципаль районы
Башлыгы карарына
2018 елның “___”
______ №________

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Советында һәм Башкарма комитетында гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау һәм шәхси кабул итүне тәэмин итү буенча

## ЭШ ТӘРТИБЕ

### 1.Гомуми нигезләмәләр

1.1.Әлеге тәртип Россия Федерациясе гражданнарының язма һәм телдән булган мөрәҗәгатьләрен (алга таба – мөрәҗәгатьләр) кабул итү, учетка алу, теркәү, аларны карауны һәм үтәлешен контрольдә тоту кагыйдәләрен билгели, мөрәҗәгатьләрдә булган мәгълүматны анализлау һәм гомумиләштерү тәртибен, мөрәҗәгатьләрнең сәбәпләрен һәм характерын ачыклауны, шулай ук Ютазы муниципаль районы Советында һәм Башкарма комитетыенда гражданнарны кабул итүне оештыруны билгели.

Әлеге Эш тәртибенең Нигезләмәләре 2006 елның 2 маеннан булган “Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында”гы 59 санлы Федераль закон (алга таба – ФЗ), Татарстан Республикасының 2003 елның 12 маеннан маеннан булган Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында”гы 16 санлы Законында билгеләнгән тәртиптә каралырга тиешле булган мөрәҗәгатьләргә кагыла (алга таба – ТРЗ).

1.2. Гражданнарның язма мөрәҗәгатьләре тәкъдимнәр, гаризалар һәм шикаятьләр төрендә керә.

1.3. Мөрәҗәгатьләрне карау Совет һәм Башкарма комитет җитәкчеләренең яки аларның язма йөкләмәләре буенча, компетенңияләре чикләрендә башка вазифаи затларның вазифаи бурычлары булып тора. Җитәкчеләр мөрәҗәгатьләрне карау буенча эшне дөрес оештыру һәм Советта һәм Башкарма комитетта гражданнарны кабул итү буенча шәхси җаваплы.

1.4. Хәл ителешләре Совет һәм Башкарма комитет компетенциясенә кермәгән сораулары булган язма мөрәҗәгатьләр, теркәлгәннән соң җиде көн эчендә тиешле органга яки мөрәҗәгатьтә куелган сорауларны хәл итү аның компетенңиясендә булган тиешле вазифаи затка җибәрелә, мөрәҗәгатьне башка адреска җибәрү турында гражданинга язма төрдә хәбәр ителә (ФЗның 11 маддәсе, 1, 4 өлешләрендә күрсәтелгән очраклардан тыш). Бу җәһәттән язма хәбәр текстында Законның тиешле маддәсенә сылтама булырга тиеш. Уведомлениенең икенче нөсхәсе делога теркәп куела.

Әгәр язма мөрәҗәгатьтә куелган сорауларны хәл итү берничә дәүләт органы, җирле үзидарә органнары яки вазифаи затлар компетенциясенә карый икән, мөрәҗәгатьнең күчермәсе теркәлгәннән соң җиде көн эчендә тиешле дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына яки тиешле вазифаи затларга җибәрелә (ФЗның 8 статьясы 4 өлеше).

1.5. Шикаятьне карарларыннан һәм гамәлләреннән (гамәл кылмауларына) риза булмыйча жалоба бирелгән дәүләт органына, җирле үзидарә органына юнәлтү тыела (ФЗның 8 статьясы, 6 өлеше).

Әлеге тыю белән бәйле, мөрәҗәгатьтә куелган сорауларны хәл итү алар компетенциясенә кергән дәүләт органына, җирле үзидарә органына яки вазифаи затка жалобаны җибәрү мөмкин түгел икән, жалоба, гражданинга кире кайтарыла һәм аның тиешле карарга һәм гамәлгә (гамәл кылмауга) риза булмыйча, билгеләнгән тәртиптә судка мөрәҗәгать итә алуы әйтелә (ФЗның 8 маддәсе, 7 өлеше).

1.6. Әгәр язма мөрәҗәгать текстын укырга мөмкин түгел икән, мөрәҗәгатькә җавап бирелми, ул алар компетенциясенә ярашлы, каралуга дәүләт органына, җирле үзидарә органына һәм вазифаи затка җибәрелергә тиеш түгел, бу турыда, әгәр дә аның фамилиясен һәм почта адресын укырга мөмкин булса, мөрәҗәгатьне җибәргән гражданинга хәбәр ителә (ФЗның 11 маддәсе, 4 өлеше). Әлеге мөрәҗәгать делога теркәлә.

Язма мөрәҗәгать тексты тәкъдимнең, гаризаның һәм жалобаның асылын аңларга мөмкинлек бирми икән, мөрәҗәгатькә җавап кайтарылмый һәм ул дәүләт органына, җирле үзидарә органына яки вазифаи затка, алар компетенциясенә ярашлы, җибәрелергә тиеш булмый, бу турыда җиде көн дәвамында мөрәҗәгатьне җибәргән гражданинга хәбәр ителә.

1.7. Язма мөрәҗәгатьне җибәргән гражданинның фамилиясе һәм җавап юнәлтергә почта адресы булмаган очракта, җавап бирелми (ФЗның 11 маддәсенең 1 өлеше). Мондый мөрәҗәгать аноним дип таныла һәм тиешле делога теркәлә.

Мондый мөрәҗәгатьтә шәхси һәм иҗтимагый куркынычсызлыкка янаган җинаятьләр һәм вакыйгалар турында мәгълүмат булса, мөрәҗәгать теркәлергә һәм тиешле компетентлы органнарга юнәлтелергә тиеш була.

1.8. Суд карарына шикаять белдереп язылган мөрәҗәгать, аны җибәргән гражданинга, әлеге суд карарыннан риза булмыйча гариза бирү тәртибен аңлатып, кире кайтарыла (ФЗның 11 статьясының 2 өлеше).

1.9. Әгәр дә кергән мөрәҗәгатьтә әдәпсез, вазифалы затны хурлый торган, аның, шулай ук аның гаилә әгъзаларының тормышына, сәламәтлегенә һәм милегенә янаган сүзләр бар икән, ул анда куелган сораулар асылы буенча җавапсыз калдырылырга мөмкин. Бу очракта мөрәҗәгатьне җибәргән гражданинга мөрәҗәгатькә хокуктан тупас файдалануга юл куелырга тиеш булмавы турында әйтелә (ФЗның 11 статьясы, 3 өлеше). Шул ук вакытта мөрәҗәгать мөһим чаралар күрү өчен тиешле органга җибәрелә.

1.10. Әгәр дә гражданинның язма мөрәҗәгатендә аңа элек сорауның асылы буенча күп тапкыр язма җаваплар бирелгән сорау язылган һәм бу җәһәттән мөрәҗәгатьтә яңа дәлилләр һәм шартлар китерелми икән, әлеге

мөрәҗәгать элек тә шул ук җирле үзидарә органына яки шул ук вазифаи затка (ФЗның 11 статьясы, 5 өлеше) җибәрелгән икән, җитәкче чираттагы мөрәҗәгатьнең нигезсез булуы турында һәм әлеге сорау буенча гражданин белән язышуны туктату турында карар кабул итәргә хокуклы. Әлеге карар турында мөрәҗәгатьне җибәргән гражданинга җиткерелә.

Әгәр дә җавабы 2017 елның 27 ноябреннән булган “Россия Федерациясендә гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында”гы 355 санлы Федераль законның 10 статьясы, 4 өлешенә ярашлы, “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникацион челтләренең Ютазы муниципаль районы сайтында урнаштырылган язма мәрәҗәгать кергән икән, мөрәҗәгатьне җибәргән гражданинга, аны теркәгәннән соң җиде көн эчендә мөрәҗәгатьтә куелган сорауга җавап урнаштырылган “Интернет” информацион-телекоммуникацион челтәрендәге рәсми сайтның электрон адресы хәбәр ителә, шул ук вакытта суд карарына риза булмыйча язылган мөрәҗәгать кире кайтарылмый.

1.11. Гражданнарны шәхси кабул итү, алдан язылу нигезендә, атна саен уздырыла.

1.12. Кабул итү урыны, кабул итү өчен билгеләнгән көннәр һәм сәгатьләр турында мәгълүмат, алдан язылу өчен телефоннар Интернет информацион-телекоммуникация челтәренең Ютазы муниципаль районы сайтында урнаштырыла.

1.13. Гражданнарны кабул итүне язу һәм учетка алу гражданнарны кабул итүне теркәү карточкасына, кушымтага ярашлы кертелә. Гариза бирүчегә кабул итүнең төгәл датасы һәм вакыты өстәмә рәвештә телефон аша хәбәр ителә.

1.14. Шәхси кабул итү вакытында гражданин аның шәхесен раслаучы документ күрсәтә (ФЗның 13 статьясының 2 өлеше).

1.15. Кабул итүче вазифаи (яки вәкаләтле) зат гражданинны игътибар белән тыңларга һәм аның мөрәҗәгате асылын җентекле аңларга тиеш.

Телдән мөрәҗәгатьтә бәян ителгән фактлар һәм шартлар аңлашылып торса һәм өстәмә тикшерүне таләп итмәсә, гражданин мөрәҗәгатенә җавап шәхси кабул итү барышында телдән бирелергә мөмкин, бу турыда гражданинны шәхси кабул итү карточкасына язма теркәлә. Калган очракларда мөрәҗәгатьтә куелган сораулар асылы буенча язма җавап бирелә (ФЗның 13 маддәсе, 3 өлеше). Шәхси кабул итү барышында кабул ителгән язма мөрәҗәгать теркәлергә һәм әлеге Эш тәртибендә билгеләнгән тәртиптә каралырга тиеш. Әгәр мөрәҗәгатьтә Совет яки Башкарма комитет компетенциясенә кермәгән сораулар була икән, гражданинга кайда һәм нинди тәртиптә мөрәҗәгать итәргә мөмкин булуы турында аңлатма бирелә (ФЗның 13 статьясы 5 өлеше).

Шәхси кабул итү барышында гражданинның мөрәҗәгатен алга таба караудан, әгәр аңа мөрәҗәгатьтә куелган сораулар асылы буенча элек җавап бирелсә, баш тартырга мөмкиннәр (ФЗның 13 статьясы, 6 өлеше).

1.16. Советның һәм Башкарма комитетның вазифаи затлары гражданнаргы шәхси кабул итү белән бәйле сораулар буенча башка җирле

үзидарә органнарына, предприятиеләргә, оешмаларга һәм учреждениеләргә мөрәҗәгать итү хокукына ия, аларның җитәкчеләре һәм хезмәткәрләре бурычлы:

- кирәкле белешмә һәм мәгълүмати материаллар тәкъдим итәргә (норматив хокукый актларга ярашлы таратылырга тиеш булмаган мәгълүматлардан тыш);
- квалификацияле консультацияләр, элемтә белән тәэмин итәргә;
- кабул итү өчен хезмәткәрләр җибәрергә һ.б.ш.

## 2.Гражданнарның хатларын кабул итү, теркәү һәм учетка алу

2.1. Почта аша килгән юлламаларга салынырга мөмкин булган шартлаучан, агулы һәм башка куркыныч нәрсәләрне табу һәм вакытында зарарсызландыру максатында, алар тышкы яктан тикшерелә. Андый нәрсәләр булуы ачыкланганда, яки алар бар дип шикләнелгәндә, хат белән алга таба эшләү туктатыла һәм куркынычсызлык органының тиешле подразделениесе белгече чакырыла. Белгеч чакырту белән бер үк вакытта почта юлламасын мәҗбүри изоляцияләү кебек чаралар күрелергә тиеш.

Террорчылык актлары һәм башка җинаятьләр кылу белән янаган язма мөрәҗәгатьләр алганда, оператив-эзләнү чаралары һәм тикшерү эшләре уздырганда файдаланырга мөмкин булган “эзләрне” саклау өчен чаралар күрелә.

2.2. Язма мөрәҗәгатьләрне кабул иткәндә, аларны адресацияләү дөреслеге тикшерелә. Билгеләнеш буенча китерелмәгән хатлар кичекмәстән почта элемтәсе предприятиесенә, тиешле адресатка җибәрү өчен ачылмаган килеш кайтарыла.

Конвертларны ачкач, анда хат һәм документлар булуы тикшерелә (ертылган документлар ябыштырыла), алар конвертка беркетелә, җибәрелгән документлар (паспорт, хәрби билет, хезмәт кенәгәсе, пенсия таныклыгы һәм башкалар, шулай ук фотосурәтләр һәм хатка башка кушымталар) хатка беркетелә. Кушымта яки хат текстының үзе булмавы ачыкланган очракта, бу турыда хат җибәрүчегә хәбәр ителә.

2.3. Советка яки башкарма комитетка кәгазьгә язылган төрдә яки электрон почта аша килгән барлык язма мөрәҗәгатьләр тапшырылган моменттан соң өч көн эчендә теркәлә һәм электрон документлар әйләнеше системасына кертелергә тиеш.

2.4. Һәр мөрәҗәгатькә тәртип буенча теркәү номеры билгеләнә. Һәр яңа календарь елда яңа тапшырылган мөрәҗәгатьләрнең нумерациясе беренче номердан башлана.

2.5. Ахыргы карарны чыгару өчен гражданин шикаятьтә (жалобада) күрсәткән мәгълүматлар җитәрлек булмаган чакта, гамәлләренә жалоба белдерелгән учреждениедән һәм заттан карар кабул ителүнең нигезлелеге турында нәтиҗә белән тикшерү материаллары сорала. Мөһим булган очракта, җитәкче күрсәтмәсе буенча урында шикаятьне тикшерү өчен җирле

үзидарә органнары хезмәткәрләренең комиссия белән баруы оештырылырга мөмкин.

2.7. Башкаручы мөрәҗәгатькә җавапка кул куйган затлар белән бер үк вакытта аның эчтәлеге, бәян итүнең ачыклыгы һәм төгәллеге, норматив актларга сылтамаларның дөреслеге өчен җаваплы.

2.8. Гражданнарның язмалары, барлык сораулары да тикшерелгән, алар буенча тиешле чаралар күрелгән һәм гамәлдәге закончалыкка ярашлы төгәл җаваплар бирелсә, хәл ителгән дип исәпләнә.

2.9. Советның һәм Башкарма комитетның җитәкчеләре һәм башка вазифаи затлары:

а) мөрәҗәгатьне объектив, төрле яклап һәм вакытында карауны тәэмин итәләр, мөһим булганда – мөрәҗәгатьне җибәргән гражданин катнашында;

б) мөрәҗәгатьне карау өчен башка дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан һәм башка вазифаи затлардан документлар һәм материаллар сорататалар;

в) гражданинның бозылган хокукларын, ирегең һәм законлы мәнфәгатьләрен тергезүгә яки яклауга юнәлтелгән чаралар күрәләр;

г) мөрәҗәгатьтә куелган сорауларның асылы буенча, ФЗның 11 статьясы 1-6 өлешләрдә күрсәтелгән очраклардан тыш, язма җаваплар бирәләр;

д) гражданинга, аның мөрәҗәгатен компетенцияләренә ярашлы карау өчен башка җирле үзидарә органына яки башка вазифаи затка җибәрүләре турында хәбәр итәләр.

2.10. Советка гомуми файдаланудагы мәгълүмати системалар буенча кергән мөрәҗәгать, Законда билгеләнгән тәртиптә каралырга тиеш (ФЗның 7 статьясы, 3 өлеше, 10 статьясы, 4 өлеше).

2.11. Мөрәҗәгатьне караган вакытта анда булган мәгълүматларны, шулай ук гражданинның шәхси тормышына кагылган мәгълүматларны, аның ризалыгыннан башка тарату тыела. Гражданинның җирле үзидарә органнарына мөрәҗәгате факты турында мәгълүмат һәм куркынычсызлык органнарында мөрәҗәгатьне карауга турыдан-туры мөнәсәбәте булмаган затларга аны карау нәтиҗәләре турында мәгълүмат таратылырга тиеш түгел. Мөрәҗәгатьтә куелган сорауларны хәл итү алар компетенциясенә кергән дәүләт органына, җирле үзидарә органына яки вазифаи затка язма мөрәҗәгать җибәрү мәгълүматларны тарату булып исәпләнми (ФЗның 6 статьясы 2 өлеше).

2.12. Гражданнарның Советка, Башкарма комитетка яки вазифаи затка кергән язма мөрәҗәгатьләре, теркәлгәннән соң, алар компетенциясенә ярашлы, 30 көн дәвамында карала.

2.13. Советка һәм Башкарма комитетка кергән мөрәҗәгатьләрне карау срогының башлануы булып аларны органда теркәү көне санала. Мөрәҗәгатьләрне карау срогының ахыры булып мөрәҗәгать авторына җавапка кул кую датасы санала.

2.14. Билгеләнгән тәртиптә каралган морәҗәгатьләр буенча карарлар чикле рәвештә таратылучы хезмәт мәгълүматына кертелә алмый.

Әгәр мөрәҗәгатьтә куелган сорауның асылы дәүләти яки Федераль закон белән саклanучы серне ачу белән бәйле икән, мөрәҗәгатьне җибәргән гражданинга анда куелган сорауга җавап бирү күрсәтелгән мәгълүматны таратырга ярамавы сәбәпле мөмкин булмавы турында хәбәр ителә (ФЗның 11 статьясы, 6 өлеше).

2.15. Язма мөрәҗәгатькә җавап район Башлыгы, Башкарма комитет җиәкчесе, район Башлыгы урынбасары, Совет Аппараты бланкында әзерләнә һәм аңа җитәкче, яки моңа вәкаләтле вазифаи зат кул куя.

Электрон документ формасындагы мөрәҗәгатькә җавап электрон документ формасында Совет яки Башкарма комитет вазифаи затына электрон документ фориасында кергән мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән электрон почта адресы, язма формада Совет яки Башкарма комитет вазифаи затына кергән мөрәҗәгатькә җавап – почта адресы буенча – язма формада җибәрелә. Моннан тыш, Совет яки Башкарма комитет вазифаи затына кергән билгесез затлар даирәсенә кагылган тәкъдиме, гаризасы, шикаяте булган, аерым алганда, билгесез затлар даирәсе мөнәсәбәтендә чыгарылган суд карарыннан риза булмыйча язылган мөрәҗәгатькә җавап 2006 елның 2 маеннан булган “Россия Федераңиясендә гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында”гы №59-ФЗ Федераль Законның 6 статьясы 2 өлеше (алга таба – Федераль закон) таләпләрен үтәп, “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә, Ютазы муниңипаль районы сайтында урнаштырылырга мөмкин.

Ике яки аннан артыграк затлар мөрәҗәгатенә (коллектив мөрәҗәгать) җавап аңа кул куйган беренче кеше исеменә җибәрелә (әгәр мөрәҗәгатьтә аерым зат күрсәтелмәгән булса) яки кайбер очракларда – мондый мөрәҗәгаткә кул куйган затларның һәрберсенә.

2.16. Гражданнар Советка яки Башкарма комитетка һәм аларның вазифаи затларына Татарстан Республикасының дәүләт телләрендә, туган телләрендә яки Россия Федерациясе халыкларының башка үзләре белгән теләсә кайсы телендә мөрәҗәгать итәргә хокуклы. Җаваплар мөрәҗәгать язылган телдә бирелә. Мөрәҗәгать телендә җавап бирү мөмкинлеге булмаган очракта, Татарстан республикасының дәүләт телләре файдаланыла (ТР Законының II бүлегенең 5 статьясы).

2.17. Советның һәм Башкарма комитетның гражданнар мөрәҗәгатьләре буенча делопроизводствосы башка төрдәге делопроизводстволардан аерым, хокукый актлар таләпләренә ярашлы алып барыла.

3. Ааерым мөрәҗәгать төрләре белән эшләү

3.1. Депутатлар мөрәҗәгатьләре.

Депутат хаты булып, кагыйдә буенча, документ бланкында язылган һәм депутат (депутатлар) имзасы куелган мөрәҗәгать санала.

Депутатлар мөрәҗәгатьләре җиде көн дәвамында карала һәм, әлеге сроктан соңламыйча, депутатка соралган мәгълүматы җибәрелә.

Депутатлар мөрәҗәгатьләре аерым контроль астына алына.

3.2. Кабаттан язылган хатлар.

Кабаттан язылган хатлар булып, әгәр беренче мөрәҗәгать китерелгән вакыттан соң закончалык белән билгеләнгән карау срогы үтеп китсә, яки мөрәҗәгать итүче аның мөрәҗәгате буенча кабул ителгән карар белән риза булмаса, бер үк кешедән бер үк сорау буенча килгән тәкъдимнәр, гаризалар һәм шикаятьләр санала.

Яңадан хат килү очрагында, аңа булган хат язышулар һәм теркәү-контроль карточкасы сайланып (теркәлеп) куела.

Бер үк авторның төрле сораулар буенча язылган хатлары кабаттан язылган мөрәҗәгать булып саналмый.

3.3. Сукырларның рельефлы-нокталы шрифтта язылган хатлары тәрҗемә итү өчен Бөтенроссия сукырлар җәмгыяте бүлекчәсенә җибәрелә. Тәрҗемә иткәннән соң, мөрәҗәгатьләр белгечләр каравына тапшырыла. Аларны карау срогы тәрҗемә кергән көннән башлап санала.

4. Ришвәтчелек юнәлешендәге фактлар буенча гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү тәртибе

4.1. Коррупцион юнәлештәге фактлар буенча гражданнар мөрәҗәгатьләре үз эченә вазифаи затларның ришвәтчеллеген һәм янап акча алу, хезмәт тәртибе таләпләрен бозу, шулай ук хезмәт урыны белән файдалану билгеләре булган башка гамәлләр кылуны ала.

4.2. Коррупцион юнәлештәге фактлар буенча Советка кергән гражданнар мөрәҗәгатьләре әлеге Тәртиптә билгеләнгән рәвештә каралырга тиеш.

4.3. Мөмкин булган коррупцион хокук бозулар турында мәгълүмат ачыкланган мөрәҗәгатьне баштагы карау процедурасын уздырганнан соң, мөрәҗәгать кичекмәстән район Башлыгына тапшырыла. Башлык резолюция сала һәм башкаручыларны билгели. Мөрәҗәгатьне карау аерым контрольгә куела.

4.4. Коррупцион юнәлештәге фактлар буенча гражданнар мөрәҗәгатьләрен караганда, анда булган мәгълүматны тарату, шулай ук аның рөхсәтеннән башка гражданинның шәхси тормышына кагылган мәглүматларны тарату рөхсәт ителми. Каралучы сорауның барлык шартларын ачыклауга кадәр мөрәҗәгатьтә куелган сорауларны хәл итү аныц компетенциясенә кергән вазифаи затка язма мөрәҗәгать җибәрү мәгълүматны тарату дип исәпләнми.

4.5. Карары яки гамәлләре (гамәл кылмавы) аны язу сәбәбе булып торган мөрәҗәгать дәүләт органына, җирле үзидарә органына яки вазифаи затка җибәрелми.

4.6. Мөрәҗәгатьтә әзерләнүче, кылынучы яки кылынган хокукка каршы гамәл, хокукка каршы гамәлне әзерләүче, кылучы зат турында мәгълүмат бар икән, мәгълүмат теркәлә һәм компетенциясенә ярашлы дәүләт органына җибәрелә.

4.7. Мөрәҗәгатьтә муниципаль хезмәткәрнең муниципаль хезмәт белән бәйле бурычларын, чикләүләрне һәм тыюларны, шулай ук хезмәт тәртибе таләпләрен үтәмәве, муниципаль хезмәткәрдә мәнфәгатьләр каршылыгына китергән һәм китерергә мөмкин булган шәхсии кызыксынучанлык булса, мәнфәгатьләр конфликты турында, муниципаль хезмәткәрнең башка ришвәтчел хокук бозулар турында мәгълүмат язылган икән, район Башлыгы, мөрәҗәгатьтә бәян ителгән фактлар мөнәсәбәтендә, тикшерү уздыруның максатка ярашлы булуы турында карарны Башлыкның коррупциягә каршы көрәш буенча ярдәмчесенең докладной язмасы нигезендә кабул итә. Әлеге тикшерү хезмәт тәртибе таләпләрен үтәүне тикшерү (муниципаль хезмәткәрнең чикләүләр һәм тыюлар, мәнфәгатьләр конфликтына юл куймау яки аны җайга салу турында таләпләрне үтәве, аның тарафыннан Татарстан Республикасы Президентының 2015 елның 2 февраленнән булган “Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт башкаруга дәгъва иткән гражданнар һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан тапшырылган мәгълүматларның дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт урынындагы тәртибенә таләпләр турында”гы №УП-71 Указына ярашлы уздырыла.

4.8. Әгәр мөрәҗәгатьтә бәян ителгән фактлар оператив-эзләү чаралары уздыру юлы белән тикшерүне таләп итә икән, мөрәҗәгатьне карау процессында оператив-эзләү эшчәнлеген гамәлгә ашыруга вәкаләтле дәүләт органнарына запрос җибәрелә.

4.9. Әгәр әлеге тикшерүне уздырганда муниципаль хезмәткәрнең эштәге тәртибенә карата таләпләрне яки мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча таләпләрне үтәмәвен раслаган фактлар ачыклана икән, район Башлыгы тикшерү материалларын Ютазы муниципаль районының муниципаль хезмәткәрләрнең, муниципаль вазифаларны үтәүче вазифаи затларның хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү, һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссиягә (алга таба – комиссия) тапшыру турында карар кабул итә.

Әлеге сорауны карау турында карар кабул иткәндә, Комиссия утырышында утырышның, датасы, вакыты һәм урыны билгеләнә, шулай ук норматив-хокукый актларга ярашлы, Комиссия утырышын әзерләү буенча эш оештырыла.

4.10. Мөрәҗәгатьтә куелган сораулар асылы буенча аны язучыга җавапта уздырылган чаралар һәм тикшерүләр нәтиҗәләре, Комиссия карарлары (булганда) буенча мәгълүмат, шулай ук күрелгән чаралар, муниципаль хезмәткәргә җаваплылык чаралары куллану, шулай ук тикшерү уздыру өчен нигез булмавы һәм ришвәтчелек фактларының расланмавы турында мәгълүмат язылырга тиеш.

4.11. Мөрәҗәгать, гражданинга мөрәҗәгатьтә куелган барлык сорауларына җавап язганнан соң контрольдән алына.

5. Гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләр торышын тикшерү һәм аларны карауны контрольдә тоту. Мөрәҗәгатьләрдәге мәгълүматны анализлау һәм гомумиләштерү

Советның һәм Башкарма комитетның вазифаи затлары үзләренең компетенцияләре чикләрендә мөрәҗәгатьләрне карау тәртибен гамәлгә ашыра, гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләр эчтәлегенә анализ ясый, гражданнарның хокукларын, ирекләрен һәм законлы мәнфәгатьләрен чикләү (бозу) сәбәпләрен ачыклау һәм аларны бетерү буенча чаралар күрә (ФЗның 14 статьясы).

5.2. Һәр квартал нәтиҗәләре буенча гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә һәм аларны карауга анализ ясау тәкъдим ителә. Әлеге анализ буенча отчет Ютазы муниципаль районы сайтында урнаштырылырга тиеш.

5.3. Советта һәм Башкарма комитетта башкару сроклары буенча каралу нәтиҗәләре турында мөрәҗәгать авторына җавап бирелергә яки тиешле органнар һәм вазифаи затлар запросы буенча мәгълүмат бирелергә тиешле барлык мөрәҗәгатьләр контрольгә алынырга тиеш.

5.4. Контроль буенча турыдан-туры эш контроль буенча вәкаләтләргә ия вазифаи затларга йөкләнә.

Мондый контрольне гамәлгә ашыручы затлар түбәндәге хокукларга ия:

а) башкаручылар һәм аларның турыдан-туры җитәкчеләреннән мөрәҗәгатьне карау барышы турында мәгълүмат сорарга;

б) билгеләнгән тәртиптә мөрәҗәгатьләрне карау торышын чагылдырган материаллар белән танышырга;

мөрәҗәгатьләрне карауга контроль барышында ачыкланган кимчелекләрдән арыну буенча тиешле вазифаи затларга тәкъдимнәр кертергә.

5.5. Мөрәҗәгатьләр белән эшләр торышы (кыскача информацион-статистик мәгълүмат, мөрәҗәгатьләр белән эшне камилләштерү буенча үткәрелгән чаралар һ.б.ш.) җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында еллык отчетларда һәм массакүләм мәгълүмат чараларында чагылдырылырга мөмкин.

Ютазы муниципаль районы
Башлыгы
карарына №2 кушымта
_______ елдан № ________

**ГРАЖДАННАРНЫ КАБУЛ ИТҮНЕ ИСӘПКӘ АЛУ КАРТОЧКАСЫ**

№ ______- ШК Кабул итү датасы «____»______________________ 20_____г.

Фамилиясе, исеме, әтисенең
исеме__________________________________________________________

Адресы________________________________________________________________________

Телефоны______________________________________________________________________

Социаль хәле__________________________________________________________

Ташламалы
состав_______________________________________________________________

Кабул итүнең кабатлануы: әйе,
юк______________________________________________________

Мөрәҗәгатьнең кыскача эчтәлеге _________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

Кабул итү
нәтиҗәсе______________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

Әңгәмәне алып
барды__________________________________________________________________

Имза_________________________________________________________________________

Телдән җавапка риза__________________________________________________

Имза__________________________________________________________________

Үтәлү турында язма

Контрольдән алынды « » ______________ 20________

Имза______________________________________________________________
—